**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 17.03.2020

**КАРАР** № 147

**«Тәтеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында»гы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 920 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Тәтеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында»гы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 920 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кушымтаның 3.3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр белән беррәттән, планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып, аерым алганда, дәүләт торак күзәтчелеге органына, гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, мәгълүмат системасы аша, гражданнар, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт, дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләрен бозу фактлары, торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки башка

махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын, торак милекчеләре ширкәте уставын төзү тәртибенә карата таләпләрне, торак милекчеләре ширкәтен, торак-коммуналь хуҗалыкны оештыру тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставына үзгәрешләр кертү тәртибе, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан, оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, юридик затны яки күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген башкаручы индивидуаль эшкуарны сайлап алу турында карар кабул итү тәртибенә (алга таба - идарәче оешма), идарәче оешма белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен төзү максатларында, идарәче оешма белән күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсен төзү турында карар, әлеге Кодексның 164 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләрне башкару буенча хезмәт күрсәтү шартнамәләрен төзү, әлеге шартнамәләрнең шартларын раслау һәм аларны төзү тәртибе турында карарлар, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми милеген карап тоту һәм әлеге йортта гомуми милекне агымдагы һәм капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру тәртибе, күпфатирлы йортта торак урынын торак булмаган бинага күчерү тәртибенә, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары, идарәче оешма тарафыннан әлеге Кодексның 162 статьясындагы 2 өлешендә каралган йөкләмәләрне бозу фактлары турында, коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендә, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллануның билгеләнгән нормативының нигезсезлеге фактларын, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларының составына карата таләпләрне бозу, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү шартларын һәм алымнарын үтәмәү, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу фактлары турында, социаль файдаланудагы наемлы йортларда торак урыннары найм алучылар тарафыннан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләрен һәм торак урыннарны найм

шартнамәләрен төзү һәм үтәү, җирле үзидарә органнары, ресурс белән тәэмин итүче оешмалар, күп фатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген башкаручы затлар, гражданнар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләрне бозу фактлары турында социаль файдаланудагы наемлы йортларда торак урыннары найм бирүчеләргә һәм яллаучыларга карата мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында. Дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органына (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына лицензия контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү очракларында) планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерү билгеләү турында Россия Федерациясе баш дәүләт торак инспекторының боерыгы (күрсәтмәсе) тора. Күрсәтелгән нигезләмәләр буенча планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә һәм планнан тыш тикшерү үткәрү турында тикшерелә торган оешмага алдан хәбәр итмичә генә үткәрелә.».

1.2. Кушымтаның 3.2.8.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлаганнан бирле, дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган билгеләмә нигезендә әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә.».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**